**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын оешкан төстә һәм үз вакытында хәрби хезмәткә чакыруны тәэмин итү максатларында, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы ФЗ-53 номерлы Федераль законның 26 һәм 27 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2016 елның 25 мартындагы ПУ-282 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 июнендә ПУ-538 номерлы, 2016 елның 29 сентябрендәге ПУ-884 номерлы, 2016 елның 20 декабрендәге ПУ-1151 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы ПУ-259 номерлы, 2018 елның 24 июнендәге ПУ-537 номерлы, 2017 елның 30 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1177 номерлы һәм 2018 елның 29 мартындагы ПУ-272 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына (алга таба – хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составыннан чыгарырга:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров һәм Мәскәү районнары буенча А.Я. Кәримовны;

Алексеевск муниципаль районы буенча И.В. Мураткинны, Л.Н. Кирюхинаны;

Әлки муниципаль районы буенча В.А. Яковлевны;

Бөгелмә муниципаль районы буенча Н.С. Моисееваны;

Зәй муниципаль районы буенча И.З. Әшрәповны, М.С. Хуҗинны;

Ютазы муниципаль районы буенча З.В. Глушкованы;

б) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров һәм Мәскәү районнары буенча Дорошкевич Тарас Святославовичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 3 номерлы «Зареченский» полиция бүлеге башлыгын;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча: Елисеев Владимир Александровичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча 1 номерлы «Автозавод» полиция бүлеге башлыгын, Кочетов Вячеслав Михайловичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча 3 номерлы «Үзәк» полиция бүлеге башлыгын, Сабиров Рөстәм Мохтар улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча 4 номерлы «Электротехника» полиция бүлеге башлыгын;

Алексеевск муниципаль районы буенча: Яковлев Вячеслав Анатольевичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге полиция башлыгын, Гыйлаҗев Дамир Әмир улын – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгын;

Әлки муниципаль районы буенча: Насыйбуллин Ришат Ринат улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе башлыгын;

Зәй муниципаль районы буенча Мәүләвиев Рәмис Рафис улын – Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туристлык идарәсе башлыгын, Шипков Николай Ивановичны – Зәй муниципаль районының Ветераннар советы рәисен;

Ютазы муниципаль районы буенча Орехов Всеволод Михайловичны – Ютазы муниципаль районында Сугыш һәм хезмәт ветераннары (пенсионерлар) советы президиумы әгъзасын;

в) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең резерв составыннан чыгарырга:

Югары Ослан муниципаль районы буенча Ф.И. Мусинаны, Н.Г. Биктаһированы;

Зәй муниципаль районы буенча Л.Я. Мачтаковны;

Түбән Кама муниципаль районы буенча Л.М. Самарцеваны;

Питрәч муниципаль районы буенча О.Н. Захарованы;

г) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең резерв составына кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш һәм Яңа Савиново районнары буенча Галина Эльза Мансур кызын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савиново районнары администрациясе балалар һәм яшьләр эшләре бүлеге баш белгечен;

Югары Ослан муниципаль районы буенча: Галимуллина Лилия Тәлгать кызын – Югары Ослан муниципаль районының мәгариф бүлеге башлыгы урынбасарын, Воронцова Екатерина Андреевнаны – Югары Ослан муниципаль районының Мәктәп укучылары йорты методистын;

Зәй муниципаль районы буенча Хәлиуллин Геннадий Сәмигулла улын – Зәй муниципаль районының Ветераннар советы рәисе урынбасарын;

Түбән Кама муниципаль районы буенча Нурмөхәммәтова Гөлнара Әбелгәрәй кызын – Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама районы Хәрби комиссариаты бүлекчәсе (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) башлыгының өлкән ярдәмчесен, аны комиссия секретаре итеп расларга;

Питрәч муниципаль районы буенча Лаврова Марина Васильевнаны – «Питрәч районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт учреждениесе әйдәүче инспекторын;

д) Зәй муниципаль районы буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе әгъзасы Л.Г. Федотованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе башлыгы».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 23 июнь
№ ПУ-459